ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.08. 2022 Олы Кайбыч ав. № 368

Хисап чорында (узган ел) «Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының норматив таләпләргә туры килә торган озынлыгы» күрсәткечен җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламентын раслау турында

Татарстан Республикасының Бүленгән ситуацион үзәген булдыру һәм эшләтү буенча эшче төркеме утырышының 2022 елның 1 июнендәге РН-12-135 номерлы беркетмәсенең 5 пунктын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Хисап чорында (узган ел) «Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының норматив таләпләргә туры килә торган озынлыгы» күрсәткечен җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламентын расларга (Кушымта).

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча җитәкчесе урынбасары Б.Р. Сәлаховка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы,
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесенең
беренче урынбасары Э.Х.Заһидуллина

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының
2022 елның 25 августындагы
368 номерлы карарына кушымта

**Хисап чорында (узган ел) «Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының норматив таләпләргә туры килә торган озынлыгы» күрсәткечен җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламенты**

## I. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге Регламент хисап чорына (узган ел) карата «Тиешле норматив таләпләргә туры килә торган җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының озынлыгы» күрсәткечен мониторинглау өчен эшләнде (алга таба - Регламент).

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында күрсәткеч нәтиҗәләрен җыю һәм мониторинглау өчен җаваплылык үзәге булып Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге (алга таба-Башкарма комитет) тора.

Күрсәткеч билгеләре турында мәгълүмат белән тәэмин итүчеләр булып Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары тора.

Күрсәткеч билгеләре турында мәгълүмат бирү формасы регламентка кушымтага туры килергә тиеш. Муниципаль район буенча агрегацияләнгән мәгълүмат аңа кергән җирлекләр мәгълүматлары нигезендә төзелә һәм регламент режимында «Идарәнең нәтиҗәлелеген бәяләү» мәгълүмат-аналитика системасында Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы белән килештерелү өчен «Гомуми файдаланудагынорматив таләпләргә җавап бирми торган җирле әһәмияттәге автомобиль юллары озынлыгының гомуми озынлыгы, процентлар» күрсәткеченең фараз күрсәткечләре аларның эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү өчен шәһәр округлары һәм муниципаль районнар башлыклары докладларын әзерләү кысаларында кулланыла. Бер үк вакытта алынган һәм тапшырыла торган мәгълүмат Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында башкарма комитет җитәкчесенең билгеләнгән боерыгы белән мәгълүмат җыю һәм мониторинглауны тәэмин итүче җаваплылык үзәге тарафыннан архивлана.

## II. Аңлатмалар аппараты

Әлеге модель актта кулланыла торган терминнар һәм билгеләмәләр «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия

Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 08 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законда китерелгән.

Форма № 3-ДГ (мо) - федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең 2021 елның 30 июлендәге 458 номерлы боерыгы белән расланган «Җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары һәм аларда ясалма корылмалар турында мәгълүматлар» федераль статистик күзәтү формасы.

## III. Мәгълүмат җыю тәртибе, сроклары һәм формалары

Күрсәткечне исәпләү өчен түбәндәге мәгълүматлар кулланыла:

норматив таләпләргә туры килә торган муниципаль районда җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының гомуми озынлыгы, транспорт-эксплуатация күрсәткечләренә хисап елының декабрь азагына, хисап елының декабрь ахырына, км;

муниципаль районда җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының гомуми озынлыгы-хисап елының декабрь ахырына, км.

Башкарма комитет Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы авыл җирлекләре башлыкларына рәсми гарызнамәләр җибәрү юлы белән җирле әһәмияттәге юллар турында белешмәләрне Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең (алга таба - Росстат) территориаль органына 3-ДГ(мо) формасы буенча тапшыру датасына кадәр бер айдан да соңга калмыйча формалаштыра.

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары белән электрон документ әйләнеше системасында яки электрон почта адресы буенча мәгълүмат.

Җаваплылык үзәгенең вазыйфаи заты кушымта нигезендә электрон рәвештә кергән мәгълүматның исәбен алып бара. Әлеге мәгълүматларны җыю һәм эшкәртү нәтиҗәләре буенча җаваплылык үзәгенең вазыйфаи заты ел саен, хисап елыннан соң килүче 25 апрельдән дә соңга калмыйча, «идарә нәтиҗәлелеген бәяләү»мәгълүмати-аналитик системасында ирешелгән күрсәткечнең әһәмияте турында мәгълүматларны тутыра.

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы авыл җирлекләренең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге авыл җирлеге администрациясенең гамәлдәге законнары, шулай ук Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль заказны урнаштыру өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актлары нигезендә махсуслаштырылган оешмалар белән төзелгән контрактлары (килешүләре) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- автомобиль юлларының техник торышын бәяләү;
- автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау;
- автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау буенча эшләр башкару;
- автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау эшләрен кабул итү.

Хисап чорында (узган ел) «Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының норматив таләпләргә туры килә торган озынлыгы» күрсәткечен җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органы эшчәнлеге Регламентына кушымта

## 1. Мәгълүматлар мониторингы формасы

| № п/п | Муниципаль район, шәһәр округы,җирлек исеме | Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының норматив таләпләргә туры килә торган озынлыгы өлеше | | |
|---|---|---|---|---|
| | | % | Юлларның гомуми озынлыгы, км | Юллар озынлыгы норматив хәлдә,км |
| 1 | Олы Кайбыч | | 39,431 | 32,466 |
| 2 | Багай | | 11,595 | 6,753 |
| 3 | Борындык | | 11,804 | 7,059 |
| 4 | Мәлки | | 11,23 | 8,727 |
| 5 | Ульянково | | 17,56 | 6,857 |
| 6 | Федоровский | | 7,307 | 7,257 |
| 7 | Хуҗа Хәсән | | 15,995 | 11,344 |
| 8 | Чүти | | 21,243 | 13,976 |
| 9 | Ябалак | | 15,57 | 9,689 |
| 10 | Иске Тәрбит | | 16,74 | 7,736 |
| 11 | Олы Подберезье | | 22,5 | 10,3 |
| 12 | Кече Мәми | | 6,636 | 3,332 |
| 13 | Мөрәле | | 13,175 | 6,31 |
| 14 | Кошман | | 11,286 | 7,5 |
| 15 | Надеждино | | 17,34 | 2,388 |
| 16 | Колаңгы | | 13,011 | 6,305 |
| 17 | Олы Урсак | | 15,773 | 4,85 |